Чыганак: Гыйззәтов, К. Таҗи Гыйззәт. Фикерләр. Истәлекләр, Хатлар. Бәхәсләр.- Казан: Мастер Лайн, 2000.- 512 б.

ландырмады. Чиксез бәхетле идем мин бу минутларда һәм бу бәхет өчен Таҗи Гыйззәткә бурычлы идем.

Китап киштәмдә күп санлы китаплар арасында, бергә яшәп, шау-гөр килеп дустанә көн иткән, иҗат иткән якын дусларымның бүләк итеп биргән китаплары бар. Менә Такташның алтын тышлы томлыгы. Беренче битендә истәлекле язма: «Якын дустым Ишморатка. *Такташ. 12/IX — 1931*».

Менә Әхмәт Фәйзинең «Чор турында җыр» китабы. Беренче биттә: «Ризага — чын мәгънәсе белән дуска. *Фәйзи. 18/1-1933*».

Менә Нәкый Исәнбәтнең «Спартак» исемендәге трагедиясе. Китапның беренче битендә язма: «Риза дус! Трагедия барлыкка китерүдә беренче тәҗрибәм булган бу әсәрне истәлек йөзеннән бүләк итәм.

*Н. Исәнбәт. 8/111-1942»*.

Күп алар. Кутуйдан, Туфаннан, Мостай Кәримнән, башка дуслардан. Шулар арасында Таҗи Гыйззәттән — «Ташкыннар» трилогиясе. Беренче биттә Таҗи кулы: «Риза дус! Истәлек өчен сиңа бүләгем. 3/111-1953 ел». Ниһаять, Таҗи улы Казбектан. Беренче биттә язма: «Кадерле Риза абый һәм Рәйсә ханымга. Тирән ихтирам белән. *Казбек. 15/IX-1975*».

Болар минем шатлыгым, горурлыгым, Гомер юлымның кадерле хатирәләре.

*(Р. Ишморатның «Дусларым, остазларым» исемендәге китабыннан. Казан. 1988. 66-70 битләр — К. Г.).*

***Р. Ишморат***

## Олы талант

Утыз биш елдан артык гомерен театр һәм драматургиягә багышлаган Таҗи Гыйззәт татар совет театры һәм драматургиясенең үсешендә иң күренекле эз калдырган драматург булды. Театрыбызның нигез ташын салып, аны үстерүчеләрдән Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин, Мирхәйдәр Фәйзи, Шәриф Камал, Фәтхи Бурнаш кебек күренекле драматургларны искә алганда, Таҗи Гыйззәт исемен атап үтмичә мөмкин түгел.

...Таҗи Гыйззәтнең язучылык, кешелек якларына хас булган сыйфатларына тукталганда, озак еллар буе, якыннан аралашып яшәгән кеше буларак, аның олы иҗади таланты, тырышлыгы өстенә, үз эшенә зур җаваплылык белән каравын күрсәтер идем.

...Таҗи Гыйззәт, драмматургия остасы, өлкән язучы һәм җәмәгать эшлеклесе буларак (ул озак еллар Татарстан Язучылар союзының драматурглар секциясе җитәкчесе һәм идарә члены бул-

ды), яшь язучыларга ярдәм күрсәтә иде. Шул нисбәттән бер мисал китереп узыйк.

1933–1934 еллар. Татар дәүләт академия театрына әле ул чакта драматургия өлкәсендә танылмаган яшь язучы Мөхәммәт Әблиев үзенең әсәрен китерде. Укыдык. Беренче һәм соңгы пәрдәсе совет чынбарлыгы чорында, ә уртадагы ике зур пәрдә революциягә кадәр булган чорда бара торган «Шәмсекамәр» исемле пьеса иде бу. Әсәрдә театрны кызыктырырлык күренешләр байтак. Күп кенә урыннары яхшы ук оста каләм белән язылган. Ләкин әсәр әле сәхнәгә куяр өчен җитлекмәгән. Бигрәк тә композициясе, сюжет төзелеше эшләнеп җитмәгән. Совет чынбарлыгында бара торган вакыйгалар әсәрнең урта өлешенә һәм, киресенчә, уртадагы өлеше алдагы һәм соңгы күренешләргә комачаулый. Без – режиссерлар коллегиясе – К. Тинчурин, З. Солтанов, Ш. Шамильский, С. Вәлиев, Х. Сәлимҗанов авторга күп кенә киңәшләр бирдек. Яшь авторга аеруча Таҗи Гыйззәтнык ярдәм итте. Ниһаять, бер-ике айдан соң Мөхәммәт Әблиев «Шәмсекамәр» пьесасының яңа вариантын китерде. Әсәр хуплап каршы алынды, репертуарга кертелде. Ул Татар дәүләт академия театрында режиссер Ш. Сарымсаков тарафыннан сәхнәгә куелды. РСФСРның халык артисткасы Галия Булатованың Шәмсекамәр образын үзенә хас осталык белән иҗат итүе күңелгә уелып калды...

Әйе, яшьләргә иҗат ярдәме күрсәтү, аларны үстерүгә, драматургияне олы юлга чыгарырга омтылу Таҗи Гыйззәтнең күркәм сыйфатларыннан берсе иде.

Әгәр Таҗи Гыйззәтнең тормыш иптәше Мәликә ханымның гаҗәеп кунакчыл һәм ачык йөзле булуы турында берничә сүз әйтмәсәм, драматург табигатендәге сыйфатлар ничектер тулы булмас кебек.

Аларның өендә язучылар, артистлар, шәһәрнең күренекле кешеләре – Таҗи Гыйззәтнең якын дуслары җыйнала иде. Әдәбият, сәнгать, театр, музыка, дөньядагы хәлләр, фән өлкәсендәге яңалыклар турындагы әңгәмәләр бүгенгедәй хәтеремдә. Аларда халкыбызның яраткан җырчысы Рәшит Ваһаповлар гаиләсе еш була иде. Танылган җырчының бигрәк тә «Фирдәвескәй», «Әлфия» көйләрен яратып җырлавы хәтердә... Таҗи Гыйззәт аның «Эшче» операсыннан Нигъмәт ариясен җырлавын аеруча ярата. Рәшит үзе дә аны гаҗәеп бер эчке тирән хис белән, бөтен күңелен биреп җырлый...

Кай җирләргә барып коя икән
Боргаланып аккан агымсу.
Бергәләшеп яшәү бик күңелле,
Аерылышу, дуслар, ямансу.
Музыка, җыр тыңлаучыларны тирән уйга талдыра.
Аерылышу, дуслар, ямансу...

Ничек уйланмыйсың ди бу сүзләрнең мәгънәсе турында? Әйе, халкыбызның талантлы язучысы, театрда Язучылар союзында бергәләп

эшләнгән якын дустыбыздан аерылуга инде ике дистә елдан артык гомер узды. Ләкин аның гүзәл эше, гаделлек өчен кирәккәндә кырыс та була ала торган көләч йөзе һаман күз алдында тора.

*(Истәлек тулырак вариантта «Татарстан яшьләре» газетасының 1975 ел, 13 сентябрендә басыла — К. Г.)*

***Шириаздан Сарымсаков***

## Әйбәт кеше, олы драматург

Таҗи аганың үзен яхшы белү — аның иҗатын дөрес аңларга да ярдәм итә дип уйлыйм.

1938 елның җәендә Түбән Осланда Әхмәт Фәйзи, әле генә язып бетергән «Тукай» драмасын укыды (ул елларда язучыларның кайберләре шунда — Түбән Осланда ял итәргә гадәтләнгән иде). Уку крестьян йортының бакчасында булды. Без шунда җиргә утырып тыңладык. Анда Шәриф ага Камал, Таҗи ага Гыйззәт, Риза Ишморат, Фатих Хөсни һәм ул вакытта республикабызның сәнгать идарәсе начальнигы булган Хәиров дигән иптәш бар иде. Әсәрнең яртысын укып, бераз ял итәргә туктагач, Таҗи ага миңа «Әйдә, Шириаздан, татарча көрәшеп алыйк, син Казакъстан кешесе, татарча көрәшнең серләрен белмисеңдер әле», диде. Без шунда ук алыша башладык. Анда булган кешеләр моны кызык күреп, көлешеп, кемдер көч биреп, озак кына карап тордылар. Алышу бер якның да җиңелмәве белән бетте. Ләкин Таҗи абый, көрәшеп туктагач, миңа карап торды да: «Син дөрес көрәшмисең бит» дип, яңадан минем билдән алып, татарча көрәшнең алымнарын күрсәтә башлады. Ул моны шундый мавыгу белән эшләде, башкалар да сүзсез генә калмадылар, һәркем үзе белгәнчә, репликалар биреп, миңа ярдәм итәргә тырышты кебек. Ул аларны күрсәткәндә, аның өчен дөньяда иң матур, иң кызыклы көрәш алымнары татарча көрәштә тупланган дип уйларга мөмкин иде. Мин шунда Таҗи абыйның авыз тутырып, рәхәтләнеп халыкча сөйләвен ишеттем. Кайбер сүзләрне әйткәндә ясаган иркен хәрәкәтләре, тавышы-



*Шириаздан Сарымсаков.*